**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1856**
**17.03.2023**

Яр Чаллы шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеш, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар, торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү буенча, шулай ук шундый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында» 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы приказының 4.1 пункты, 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеш фаразы, шәһәр Уставының 41 статьясындагы 9 өлешнең 4 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. 2023 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 5,5% күләмендә билгеләргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов